Azatlıq Radiosı

ЧИТАЕМ НА ТАТАРСКОМ

# Истанбул мәктүпләре (Стамбульские письма) — Фатих Кәрими

әле генә




Сегодня в рубрике "Читаем на татарском" мы знакомимся с произведением татарского писателя, журналиста Фатиха Карими "Истанбул мәктүпләре" – "Стамбульские письма". Книга была написана в 1913 году на основе его репортажей из Стамбула, где он работал корреспондентом во время Балканских войн.

В книге автор рассказывает о жизни Стамбула, о его жителях, как они переживали войну, описывает и жизнь татар того времени.

Предлагаем прослушать несколько интересных отрывков из этой книги. Текст сокращен и адаптирован для изучающих язык.




↗ аудио уйнаткыч

йөкләү

9 нчы ноябрьдә җомга көн кич, безнең пароход Истанбул бугазына килеп кергәндә, сирәк-сирәк кенә туп тавышлары ишетелә иде. Одессада "Истанбулны болгарлар тупка тоталар икән" дигән хәбәрләрне ишетеп килгән кешеләргә җитә калды. Юлчылар: "Харап булдык, туп астына килеп керәбез бит", – дия башладылар. Әмма Истанбул әхвәлен белгәннәр: "Курыкмагыз, әфәнделәр, мөселманнарның Корбан бәйрәмедер, алар бәйрәмдә туп аталар", дип курыккан кешеләрне тынычландырдылар.

Һәйбәт җылы кояшның астыннан ике ягы да ямь-яшел бакчалар һәм агачлардан гыйбарәт Бугаз эченә килеп кергәч, ант итәмен, бер кешенең дә күңелендә сугыш куркулары калмагандыр. Бугазның ике сахилендәге искиткеч дәрәҗәдә матур манзаралар һәркемнең күңелен дә, күзләрен дә үзләренә җәлеп иттеләр. Йөз мәртәбә күреп үткән кешеләр дә йөз беренче мәртәбә булганнар да тагын ук шул әүвәлгесе шикелле тамаша итәләр иде.

Истанбулга җитеп бугаз эченә кергәч тә, пароходның бер ягыннан икенче ягына йөгерә-йөгерә ике як сахилне карый башладык. Бер генә җирне дә күрмичә калдырасы килми. Сахил шулкадәр гүзәл вә шулкадәр латыйф. Иптәшләрем Гөлсем, Рокыя вә Мәрьям ханымнар Истанбулга беренче мәртәбә киләләр, Бугаз Эчен беренче мәртәбә күрәләр, шул сәбәпле Бугаз Эченең сахилләрнең гүзәллеге аларның бигрәк тә хушларына китте.

"Кай җире моның бу кадәр күңелләрне җәлеп итә?" – дип сорадым. "Бөтен природасы гүзәл, әнә шуның өстендәге биналары, һәйбәт сарайлары вә шулар белән бергә тора торган җимерек өйләре, хәтта тәрәзәләреннән чыгарып кибәргә элгән керләре дә гүзәл, бөтен җире гүзәл", – дия җавап бирделәр. Аларның бу җаваплары бик дөрес вә бик хаклы иде.

Инде мин Истанбулны өченче мәртәбә күрәм, тагын нинди гүзәллек өстәлгән дип күрергә телим. Истанбул байтак үзгәргән. Баба Гали урамының ике ягында тротуарлар бар. Урамга түшәлгән таш, тигез, йөрергә уңайлы гына. Урамның ике ягында фонарьләр бар. Кычкырта-кычкырта автомобильләр үтеп китә. Урамнарның кайсылары бераз киңәйгән. Зур биналар арткан. Баба Гали

урамындагы дүрт-биш катлы, гүзәл биналы "Мәсәррәт" отеле урынында элек кечкенә бер кибет бар иде. Мәктәптән чыкканда кайвакытларда без аның кибетенә кереп 10 паралык пәйнир белән 10 паралык икмәк ашый торган идек.

"Мәсәррәт" отелена барганда, урамның ике ягыннан һич санап бетермәслек дәрәҗәдә күп булган каһвәханәләрдә шулкадәр күп халык утыра иде, һич берсендә аяк басарлык җир юк. Каһвәханәләрнең эчләре генә түгел, тышлары да тулган: эскәмияләре куеп, тротуарларга утырганнар. Барысы да гаять таза, шәп, матур төрекләр, гаять кибар киенгәннәр һәм бик ару сымак утыралар. Ихтимал ки, бүген бәйрәмдер дә, шуның өчен шулай утыралар да, дидек.

Урамнарда моннан 15 ел элек мин күргәндәге шикелле, ике ягына корзинка аскан һәм шул корзинкаларга туфрак, ком, таш тутырган ишәкләр дә көтү-көтү булып баралар. Көянтәгә эчәкләр, бавырлар, үпкәләр аскан "сәүдәгәрләр" дә шул ук Баба Гали урамыннан кычкыра-кычкыра үзләренең "товарларын" сатып йөриләр. Аларның пычраклары җиргә тама, өскә тия, ләкин берәүнең дә моңа эче пошмый.

Минем отельнең мөдире Мостафа әфәнде атлы бер төрек. Отель Истанбулның Аурупа ягындагы номерларның иң беренчесеннән санала. Эмма эчендә мич юк, ашарга ресторан юк, чәй эчәргә самавыр юк, ванна юк, телефон юк, подъемный машина юк. Ләкин боларның юклыгы өчен бернәрсә дә әйтеп булмый. Чөнки Истанбул ягындагы отельләрнең берсендә дә болар юктыр. Чәйне монда бездәге кеби самавырдан эчмиләр. Каһвә эчәләр. Ашханәләр урам тулы. Номерда ресторан булмаса да ярый. Мич урынына мангал ягып, шуның тирәсендә җылынып утыралар.

Тик менә бер әйбер – бүлмә эчендә язу язарга өстәл юк, юынырга умывальник та юк. Коридорга чыгып Җәмали харчевнигындагы шикелле общий краннан юынырга кирәк. Бу да бер авыр әйбер булмас иде дә, ләкин минем коридордагы кран бозылган. Су тамып кына ага. Юыну читен. Төзәттерергә үтенеп хезмәтчеләр аркылы әллә ничә рәт конторга әйттердем. Юк, төзәлми. Ниһаять, үзем Мостафа әфәндегә шуны төзәттерергә ике-өч мәртәбә әйттем. "Бакарыз, карарбыз, әфәндем, пәки" ди дә кала. Кран төзәлми... Инде әйтә: "Әфәндем, икенче коридорга барып юынсагыз булмасмы", ди. Я Рабби, әйтерсең аның краны минем өчен генә кирәк. Номерларда әллә никадәр кеше бар. Аларның рәхәтләрен дә күрергә кирәк иде бит. Моңа бер дә эчләре пошмый.

Язу язарга өстәл сорадым: "Юк, әфәндем, нә япалым", – ди. Алдыртып куй дидем. Ниһаять, простой бер өстәл ал, акчасын үзен бирермен, дидем. Булмады. Язуны берничә көннәр мәдрәсәдәге шикелле тез өстенә куеп язарга туры килде. Ахырында грек хезмәтче малае үзлегеннән бер такта өстәл табып китереп юып

бирде. Өстенә аннан-моннан кәгазьләр каплап мине сөендереп, үзенә күп кенә чәйлек алып китте. Болар бик вак, әһәмиятсез нәрсәләр. Ләкин Мостафа әфәнделәрнең дәрәҗәләрен күрсәтә торган галәмәлләр.

***

Без кызларны кунакханәгә урнаштырдык, аннары алар эшләргә тиешле хастаханәгә бергәләп киттек. Бу Истанбулда Мәрмәрә диңгезе буенда, Кадырга мәйданында гаять зур берничә биналардан гыйбарәт икән. Бу биналар эчендә элек акушеркалар мәктәбе булган. Ләкин сугыш чыккач, аларны яраланган солдатлар өчен больница ясаганнар. Анда безнең ханымнарны бик гүзәл кабул иттеләр. Монда хезмәт итүче докторларның берничәсе ирләр булып, калганнар - барысы да хатыннар. Минем газета мөхбире икәнлегемне белгәч, хастаханәләренең һәр тарафын вә яраланучылар яткан бүлмәләрен барысын да күрсәтеп чыктылар. Хастаханә бик пакь. Тәрәзәләре гаять зур булып ифрат якты. Бүлмәләр биек, һава күп. Яраланганнар өчен бик яхшы караватлар куелган. Караватларда йомшак вә пакь сырмалар вә һәйбәт одеяллар. Авыручыларның өс-башларына кигән нәрсәләре сөт шикелле ап-ак.

Бер бүлмәдә офицерлар ята икән. Төрлесе төрле җирдән яраланган. Бер майорның сул күзенә ядрә тиеп, бөтенләй агып чыккан. Һич берсендә тавыш-тын юк. Сабыр итәләр. Кайсы кырын ятып тора. Хастаханәнең мөдире дә, докторлары бик нәзакәтле һәм тәрбиялеләр. Төрекчәдән башка французча да сөйләшәләр.

Яралы солдатларны карар өчен Русиядән килгән марҗа белән дә шунда күрештек. Елизавета Николаевна, үзен княгиня Оболенская диде. Үзенең асыл мәскәүле булып, соң вакытларда Тулада фельдшерлык итеп торганын сөйләде. Яше утызлар тирәсендә булса кирәк.

— Русларда славян хисләре нык хөкем сөргән вакытта сез ничек монда килергә исәпләдегез? — дидем.

— Мин кешелеклек тарафдарымын, төрекләрне сөямен, төрекләрдән дусларым күп, шуның өчен мин монда — диде.

Истанбулның һич бер җирендә трамвай, арбалы атлар йөрми. Чөнки атлары гаскәргә, ирләрнед күбесе солдатка алынган. Болай да атлар гаскәргә алынып бик аз калган. Шул сәбәпле извозчик табып булмый. Истанбулда кич сәгать 10нан соң кешеләр урамга чыкмыйлар, тоталар да алып китәләр. Сугышка. Шуңа күрә Истанбулда кич сәгать 9 да урамнарда тормыш туктап кала. Кич сәгать 6ларда һәммә кибетләр ябылып бетә диярлек. Ашханәләр белән каһвәханәләр генә 7-8 ләргә кадәр сузыла.

***

Сугыш мәйданына китәргә рөхсәт сорап, хәрби министрлыгына мөрәҗәгать иткән идем. Берничә сынаулар аркылы үткәннән соң, ниһаять, 13 нче ноябрьдә хәрби министрының урынбасары Фоад паша хозурына кердем. Мин кергәндә, аны көтеп торучы офицерлар бик күп иде. Аларның эшләре бетеп, нәүбәт миңа җиткәнче берәр сәгать үтте. Фоад паша кыска гына буйлы бер кеше. Башында гаскәри бүрек. Күзендә күзлек. Зур залда бер өстәл янына утырган. Янында телефон. Минут саен, әле аннан, әле моннан үзе белән сөйләшә торалар. Офицерларның кулларында кәгазьләр бар. Үз нәүбәтләре җиткәч, шуны китереп бирәләр. Фоад паша тиз генә укый да кәгазьнең читенә бер нәрсәләр язып, үзләренә кайтарып бирә тора. Сөйләшү-фәлән бик әз.

Нәүбәт миңа җиткәч: үземнең русияле бер газета мөхбире булганлыгымны вә сугыш мәйданына китәргә теләгемне бәян итеп, шуңа рөхсәт бирелүен үтендем.

— Мөхбирләргә анда барырга рөхсәт бирелми, электән барганнарын да кайтардык, хәзер анда сугыш юктыр, әгәр яңадан башланса, ул вакыт карарбыз, — диде.

Мин чыгып киттем. Хәрби эшләр министрлыгы Истанбулның Баязит мәйданында урнашкан.

Мин Истанбулга килгәннән бирле һәр көн Анадолу якларыннан әллә никадәр гаскәр килеп, Серкеджи вокзалыннан сугышка таба озатыла тора. Бу вокзал мин торган "Мәсәррәт" отелена күрше генә булганлыктан, һәр көн күрергә туры килә. Солдатларны кичкә таба караңгы төшкәч җибәреләләр. Бөтен урамнарны яңгыратып җырлыйлар. Кулларында корал-фәлән юк. Кием вә коралны сугыш мәйданына якын җирдәрәк бирә торганнардыр. Араларында бик яшь бала кебек булганнары да, өлкән вә картлары да бар. Болар киткәндә урамга халык җыела. Ике яктан карап сәер итеп торалар. Мөселманнарның боларга чын күңелдән мәхәббәт белән, өметләр баглап караганлыклары әллә кайдан беленеп тора. Кайберләренең күзләреннән яшьләре тама.

Сүз уңаеннан, Йосыф әфәнде Акчурин сугышка киткән, Чаталҗа янында Хадим авылында диделәр. Аның иптәше Фәрид әфәнде дә киткән. Бу кеше – Төркия һәм Париж университетларына тәмамлаган зат.

Хәзергә Истанбулда тыныч. Янгын, талау, үтерү-кисү кебек нәрсәләр азайган, диләр. Әмма ваба чире дәвам итә. Ләкин чит газеталар язганча көчле түгел. Мәсәлән: "Одесские новости"ның: Истанбул белән Чаталҗа арасында аяк басарлык урын юк, вабадан, чумадан үлгәннәр белән тулыдыр дигән хәбәрләре катгый суратттә ялгандыр.

Үзем кичә генә ат белән Әдернә капкалырыннан Истанбулның тышына чыгып, Макры авылына таба берничә чакрым бардым. Анда һич нәрсәләр юк. Носилка белән күтәреп китерелүче бары бер авыру очрады. Ул да вабамыдыр, башка авырумыдыр, мәгълүм түгел иде.

Монда килеп үз күзең белән күргәннең соң рус һәм Аурупа газеталары мөхбирләрен дә кайберләренең Төркия, төрекләр хакында шулкадәр ялган, ялгыш нәрсәләр язуларына хәйран каласың. "Times" һәм "Daily News" газеталары Төркиягә каршы бик каты мәкаләләр нәшер иттеләр.

***

"Айя-Суфия" мәчетеннән авыру гаскәриләр чыгарылган. Мөһаҗирләр кертелмәгән. Ләкин әле эчендә намаз кылынмый, кереп йөрергә мөмкин түгел. Эчен тазарталар, дезинфекция ясыйлар, намазлыкларын җәяләр. Ишек алларын чистарталар. Капкалары ачыктыр. Солтан Әхмәд мәчетендә дә намаз кылынмый. Эчендә мөһаҗирләр бар. Идәнендәге намазлыклары алынып куелган. Бичара мөһаҗирләрнең хатын-кыз һәм бала-чагалары таш идән өстенә юка гына бер чаршау җәеп бөрешеп утырганнар. Мәчетнең гүзәл мәрмәр баганалары арасына баулар тагып балаларның бишекләрен асканнар. Шуларны тирбәтеп утыралар. Өчәр-дүртәр яшьлек сабыйлар яланаяк вә күбесенчә ыштансыз-нисез салкын таш өстендә боегып утыралар.

Хәзер генә шул мәчеттән кайттым. Мөһаҗирләрнең бер-икесеннән ашарыгызга, эчәрегезгә бармы? Бирәләрме? дип сорадым.

— Аллаһ дәүләткә, милләткә рәхмәт яудырсын. Бирәләр, өлкәннәргә һәр көн 3 кадак, балаларга кадак ярым икмәк бирәләр, чок шөкер, әлхәмдүлилләһ, — ди.

— Шурпа, балаларыгызга сөт кебек нәрсәләр бирелмиме соң, алар ничек яшиләр? — дидем.

— И, кардәш, андый нәрсәләрне төштә күрергә дә юк инде, әгәр шул икмәк тукталмаса, бик разыйбыз, — ди.

Шунда йөрүче бер төрек хезмәтчесеннән бу кешеләрнең монда нишләп тотылганнарын һәм кайчан җибәреләчәкләрен сорадым.

— Солых булгач, боларны кире үз мәмләкәтләренә кайтарып җибәрәчәкбез, шуңа кадәр монда торалар инде, — ди.

***

Истанбулны үзенең кочагына алган вә латыйф дулкыннары белән яр буйларын сөеп торган Мәрмәрә диңгезе элек безнең татарларның "Зиләйлүк" вә "Тәфтиләү" көйләрен ишеткәне бармыдыр, юкмыдыр, мин аны белмим. Әмма шушы ел мартның 5 ндә ул аларны ишетте һәм бик яратып тыңлады. Моңа мин үзем шаһитмен.

Кояш баеп килә, диңгез өсте тыныч иде. Шул вакытта яралылар карарга барган иптәшем Исмәгыйль әфәнде Урманов белән без икәү Солтан Әхмәд мәчете артындагы Мәрмәр диңгезгә таба карап утырган идек.

Һәр тараф тын, һава гаять гүзәл вә җылы, бу гүзәл һаваны иснәгән саен кешедә хәят арта, рух күтәрелә. Май дәрьясында йөзгән шикелле үзеңдә бер йомшаклык, күңелдә бер рәхәтлек хис итәсең.

Каршыбызда Мәрмәр диңгезе җәелеп ята. Босфор күренә. Аның уң ягында Үскүдар, Кадыкөй, Муданья борыны, Фәнәр борыны тезелешеп торалар. Фәнәр борыны Мәрмәрәнең эченә сузылып чыккан. Аның тәмам диңгезгә озайган җирендә диңгез фонаре куелган. Ул да яндырылды. Диңгез өстендә кечкенә бер пароход бара. Пароходның артына өч баркас такканнар, боларга гаскәр азыгы төйияләр дә китәләр. Пароходның морҗасыннан чыккан куе төтене артка таба сузылып әллә никадәр озаеп бара.

Тирә-ягыбызда күз күреме кадәр җирләр барсы да хәрабә. Ташлык. Җимерек биналар. Болар быелтыр ук янганнар. Һичберсе яңадан салынмаган, тазартылмаган, янгыннан соң ничек булган, шулай торалар.

Кая соң боларның ияләре? Ник боларны төзәтмиләр һәм яңадан салмыйлар? Бу сораулар безнең күңелгә килә. Әмма җавапларын белмибез. Ихтимал ки, ияләре үзләре дә белми торганнардыр. Бу җирләр элек мөселман мәхәлләсе булган. Бу янган йортларның ияләре дә мөселманнар булырга тиеш.

— Аһ, бу фәлсәфәләр, батырды безнең шәрык дөньясын, без төш күрәбез, аурупалылар эш күрәләр. Әйдә, Исәгыйль әфәнде, сузып җибәр үзебезнең "Зиләйлүк"не, — дидем.

Мәрмәргә карап торган иптәшем Исмәгыйль әфәнде уянып киткән төсле булды вә моңаеп нечкә көй белән "Зиләйлүк"не сузып җибәрде. Моңлы татар көе безнең күңелләрне тетрәтте, зиһеннәрне Кара диңгезнең төньяк тарафына ерак-ерак җирләргә, Волга, Урал, Кама буйларына илтеп ташлады. Күз алдыбызга кыргыз

далалары, башкорт сахралары килде, колагыбызда курай тавышлары ишетелгән төсле булды.

Җимерек бер ташка менеп утыргач:

— Эх, юк бит үзебезнең скрипка, бер сыздырып җибәреп, үзебезнең моңлы көйләребезне Мәрмәрнең шушы дулкыннарына катнаштырып җибәрер идем, шуннан алар мәңгелеккә барып кушылырлар иде, — диде Исмәгыйль әфәнде вә бер көрсенеп куйды.

Без утырган җиребезнең астында бер землянка бар икән. Әллә кайдан бер тишектән гаять алама киенгән, өс-башлары бик начар ике хатын килеп чыктылар. Яннарында бер бала бар. Болар ислам хатыннарымы, христианмы, мәгълүм түгел. Йөзләре ачык. Безнең янгарак килделәр дә бераз тыңлап торгач: "Bu ne lisanda şarkı çağırıyorsunuz, beyefendi, söyleyiniz Allah için" — диделәр.

— Татарча, — дидек.

— Nedir o Tatar, sanki Moskof mudur? — дип сорадылар.

Нәрсә икәнен аңлаттык. Соңрак болар безгә: "Бәк әфәнделәр, безне дә Русиягә алып китегез" димәсеннәрме!

— Анда нишләмәкче буласыз? — дидем.

Үзләренең хикәяләрен сөйләргә тотындылар. Болар Лүлә Боргас янында бер төрек авылыннан, төрек хатыннары икән. Ирләре солдатка алынган. Авылларына болгарлар килә башлагач, болар балачагаларын күтәргәннәр дә Истанбулга таба качканнар. Соранып, теләнеп яшиләр.

Русиягә алып китә алмавыбызны аңлаттык. Кесәбездәге биш-ун тиен бар иде, балаларына сәдака итеп бирдек тә бу җирдән аерылдык. Шулкадәр хәрабәләр эчендә ач вә пычрак, бәхетсез хәлдә ята торган бу бичараларны күргәч, безнең "Зиләйлүк" көйләре онытылды.

## Кто такой Фатих Карими?

Фатих Кәрими (1870–1937) – татарский писатель, журналист, педагог и общественный деятель. Он выступал за реформу образования, развитие национальной литературы и просвещения, писал художественные произведения, публицистику и учебные книги, а также много лет был редактором газеты "Вакыт" – одной из самых влиятельных татарских газет своего времени.

Карими учился в Стамбуле, путешествовал по Европе и написал более 100 книг и учебных пособий. Одним из его самых известных произведений стала книга **"Истанбул мәктүпләре"**. Она была написана в 1913 году на основе его репортажей из Стамбула, где он работал корреспондентом во время Балканских войн. В книге автор рассказывает о жизни города, событиях того времени и будущем мусульманского мира. Сегодня это произведение считается не только литературным, но и ценным историческим источником, которым пользуются историки.

В 1937 году Фатих Карими был репрессирован по ложным обвинениям в шпионаже и контрреволюционной деятельности. 27 сентября того же года его расстреляли в Москве. В 1959 году он был полностью реабилитирован.

## "Истанбул мәктүпләре" – больше, чем просто книга

Сегодня "Истанбул мәктүпләре" можно читать не только как путевые заметки, но и как свидетельство невероятно высокого уровня татарской журналистики начала XX века.

- **У татарских СМИ были собственные зарубежные корреспонденты.** В 1912 году газета "Вакыт" отправила своего главного редактора Фатиха Карими в Стамбул специально для освещения Балканской войны. Для национальной газеты того времени это было исключительным явлением.
- **Командировка длилась несколько месяцев.** Редакция могла позволить себе содержать журналиста за границей на протяжении четырех месяцев, чтобы читатели получали информацию непосредственно с места событий, а не в пересказе российских или европейских газет.
- **Татарские читатели получали международные новости на родном языке.** Карими отправил более 70 писем и репортажей, которые публиковались в газете "Вакыт" и журнале "Шура". Это была фактически первая татарская международная журналистика.
- **Фатих Карими был по-настоящему международным журналистом.** Он свободно владел татарским, русским, турецким, арабским, персидским и французским языками. Благодаря этому он общался с местными жителями, политиками, писателями и учеными без посредников и писал не по чужим материалам, а по собственным наблюдениям.

**"Истанбул мәктүпләре" – это репортаж, тревелблог и исторический документ одновременно.** В книге есть не только описание войны, но и рассказы о повседневной жизни Стамбула, интервью с современниками и размышления автора о будущем

Османской империи и мусульманского мира. Именно поэтому историки до сих пор используют ее как источник по истории Турции начала XX века.

**"Вакыт" и "Шура" были крупнейшим татарским медиапроектом своего времени.** Газета и журнал имели собственную типографию, широкую сеть авторов и корреспондентов, публиковали материалы о событиях в России, Европе и Османской империи. По уровню организации это были современные национальные медиа, сопоставимые с крупными изданиями своего времени.

- За время командировки Карими написал более **70 писем и репортажей,** которые публиковались в газете "Вакыт" и журнале "Шура" – крупнейших татарских изданиях начала XX века.
- Фатих Карими выдвигается в путь из Оренбурга в Самару, в Тулу на поезде. Он доезжает до Харькова, потом до Одессы. Там он живет три дня. Получает визу у консула на въезд в Стамбул. Потом уже на пароходе он доплывает до вечного города всех времен – до Стамбула. Примечательно, что на пароходе с ним плыли с Стамбул четыре татарки - **Уммугульсум Камалова** из Чистополя (дочь знаменитого ишана Закира Камалова, родственница классика татарской литературы **Фатиха Амирхана**), **Марьям Якупова** из Ташкента, **Рукия Юнусова** из Питербурга, **Марьям Поташова** из Ростова. Все они студентки Петербургской школы ехали как медсестры-волонтеры для помощи с раненым солдатам армии Османской империи во время Балканской войны.

Таким образом, история этой книги напоминает, что уже более ста лет назад татарская журналистика была частью мирового информационного пространства.

***

У нас есть и другие интересные тексты про путешествия:

- "Безнең өй өянкеләр астында иде" (Наш дом стоял под ивами) — Миргазыян Юныс
- "Бездән яшерен зәңгәр дөнья" (Тайный голубой мир) — Миргазыян Юныс
- Мисыр пирамидалары (Египетские пирамиды) – Миргазыян Юныс

Если у вас есть предложения по текстам, то Вы всегда можете оставить их по адресу: **eydetat@gmail.com**

Заходите на наш сайт, каждый день вы найдете что-то новое и интересное! Также подписывайтесь на наши соцсети: мы есть в Telegram-е, Instagram-е, Youtube и Тиктоке.

Скоро – больше! До встречи, сау булыгыз!

This item is part of

Әйдә! Online

читаем на татарском

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар саклanган